МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_30.12.2016_ г.Казань № 436

Дәүләт ярдәмен дәгъвалаган инновацион проектлар бирү Тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасының 2010 елның 02 августындагы «Татарстан Республикасында инновацион эшчәнлек турында» 63-ЗРТ Законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасында инновацион проектлар гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. Дәүләт ярдәмен дәгъвалаган инновацион проектлар бирү Тәртибе.

2. Дәүләт ярдәмен дәгъвалаган Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары гамәлгә ашырган инновацион проектларның ел саен исемлеген төзү буенча эш төркемен булдырырга, аның составын расларгав (кушылып бирелә) (алда – Эш төркеме).

3. Эш төркеменә 30-көн эчендә Эш төркеме эшенең срогын һәм регламентын эшләргә һәм расларга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольгә алуны министр урынбасары Б.З.Хаҗиәхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
Боерыгы белән расланган

№ 436

Дәүләт ярдәмен дәгъвалаган инновацион проект бирү
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип дәүләт ярдәмен дәгъвалаган инновацион эшчәнлек субъектларының (алда – Мөрәҗәгать итүчеләр) Татарстан Республикасы икътисады үсешенең приоритет юнәлешләре кысасында инновацион проектларын бирү тәртибен раслый.

2. Дәүләт ярдәмен дәгъвалаган инновацион проектлар гамәлгә ашыручы мөрәҗәгать итүчеләр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы – инновацион эшчәнлек өлкәсендә вәкаләтле органга (алда – Министрлык) дәгъвалаган дәүләт ярдәменең формасын һәм күләмен күрсәтеп заявка бирәләр.

Заявкага түбәндәге документлар беркетелә:

моннан алдагы ел өчен «Оешманың инновацион эшчәнлеге турында белешмәләр» 4нче-инновация статистик формасы (зур һәм урта оешмалар өчен);

«Кече предприятиенең технологик инновацияләре турында белешмәләр» 2нче-МП инновация статистик күзәтчелеге формасы (кече предприятиеләр өчен);

оешмалар раслаган оештыручының документлары, аларга кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр күчермәләре;

инновацион проектның бизнес-планы.

3. Мөрәҗәгать итүчеләр үз инициативалары белән түбәндәге документларны тәкъдим итә алалар:

юридик затның дәүләт теркәве турында таныклыгы күчермәсе;

салым органында исәпкә куелуы турында таныклык күчермәсе;

юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан алынган күчермәсе;

«Инновацион активлык индикаторы» интеграль индикатор мәгънәсе турында белешмә (яисә расланган күчермәсе).

4. Мөрәҗәгать итүче әлеге Тәртипнең 3нче пунктында күрсәтелгән документларны бирмәсә, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати элемтә тәртибендә соратып ала.

5. Министрлык:

документлар беркетелгән заявканы килгән көнне электрон документлар әйләнешендә кабул итә һәм терки;

заявка теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә тәкъдим ителгән документларны әлеге Тәртипнең 2нче пунктына ярашлы рәвештә карый һәм Эш төркеме карамагына тапшыра.

6. Заявкалар расланган регламентка ярашлы рәвештә, Эш төркеме тарафыннан билгеле тәртиптә карала.

7. Эш төркеме раслаган инновацион проектларны Министрлык Эш төркеме карар кабул иткән көннән алып өч көн эчендә Татарстан Республикасы инновацион проектларының төзелүче исемлегенә кертә.

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
Боерыгы белән расланган
30.12.2016 № 436

Дәүләт ярдәмен дәгъвалаган Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары гамәлгә ашыра торган инновацион проектларының исемлеген ел саен төзү буенча Эш төркеменең
составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Хаҗиәхмәтов<br>Булат Зөфәр улы | Министр урынбасары – Эш төркеме рәисе |
| 2. | Родина<br>Ольга Викторовна | Инвестицион һәм инновацион эшчәнлек Идарәсе җитәкчесе |
| 3. | Хәбибуллина<br>Лилия Шарифҗан кызы | Инновацион эшчәнлек бүлеге җитәкчесе |
| 4. | Миңнуллин<br>Юлай Рим улы | Икътисади анализ һәм проект идарәсе җитәкчесе |
| 5. | Шакиров<br>Динар Рәфыйкъ улы | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын яклау һәм институтлары үсеше бүлеге җитәкчесе |
| 6. | Самсонова<br>Виктория Владимировна | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының максатчан программалар бүлеге җитәкчесе |
| 7. | Сабирова<br>Регина Әсхәт кызы | Стратегик үсеш бүлеге җитәкчесе |
| 8. | Сәлимов<br>Радий Илдус улы | «Татарстан ЦНТИ» ТР ДУП генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| 9. | Сиражиев<br>Равил Раид улы | Россия инновацион регионнары Берләшмәсе Фонды җитәкчесе (килешү буенча) |
| 10. | Әхмәтов<br>Ленар Раил улы | «Кама кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының кластер үсеше үзәге» АНО җитәкчесе (килешү буенча) |